ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

КАРАРЫ

27 апрель 2019 ел №218

"Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы муниципаль милегенә ия булу, файдалану һәм аның белән эш итү тәртибе турында" Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, "Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советының 2009 елның 11 сентябрендәге 442 номерлы карары белән расланган "Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы муниципаль милегенә ия булу, файдалану һәм эш итү тәртибе турында" гы карары белән расланган "Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы муниципаль милегенә ия булу, файдалану һәм эш итү тәртибе турында" Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3.1. Муниципаль милек (җирле бюджет һәм бюджеттан тыш фондлардан тыш) Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә муниципаль милек реестрында мәҗбүри исәпкә алынырга тиеш.".

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Апас муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы Рәисенә йөкләргә.

Апас муниципаль районы башлыгы –
Муниципаль район Советы Рәисе Р.Н. Заһидуллин